| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.12.2025 № 1482

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районында муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары җитәкчеләренә һәм белгечләренә, баш бухгалтерларына һәм бухгалтерларына (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2023 елның 31 гыйнварындагы 91 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Нурлат муниципаль районында муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләренең һәм белгечләренең (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2025 елның 27 октябрендәге 03-12/7278 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварындагы 91 номерлы карары белән расланган Нурлат муниципаль районында муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренә һәм белгечләренә, баш бухгалтерларына һәм бухгалтерларына (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 16 августындагы 949 номерлы, 2024 елның 07 ноябрендәге 1346 номерлы, 2025 елның 30 апрелендәге 471 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Нурлат муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренең һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары баш бухгалтерларының һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) вазыйфаи окладлары " түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазифаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение | Башкарма комитетның (җирле |

| | | |
|---|---|---|
| | булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 40 700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 38 100 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 38 100 |
| Бүлек башлыгы | 33 600 | 33 600 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 30 600 | 30 600 |
| Бухгалтер | 29 000 | 29 000 |

2. «Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директорына һәм муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин